КАДИРОВА Э.Х.
(КФУ, ф.ф.к., доц.)

# XVI – XVII ГАСЫР ПОЭЗИЯСЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР

Борынгы чорларда ук фразеология әдәби әсәрнең тел тукымасын оештыруда иң актив сурәтләү чараларыннан санала. Аларның кулланылыш үзенчәлекләрен, стилистик функцияләрен билгеләү авторларның иҗат методы үзенчәлекләрен ачарга мөмкинлек бирә. Сүзләрне еш кына күчерелмә мәгънәдә кулланган, әсәрләрендә әйтергә теләгән фикерләрен һәрвакыт фразеологик әйтемнәр, тапкыр сүзләр, мәкаль-әйтемнәр белән күрсәтеп биргән шагыйрь Мөхәммәдьяр иҗатында да без аларның матур үрнәкләрен күрәбез: *башына йитү* (Т.м.), *форсат табу* (Т.м.), *сүзне сузу* (Т.м.), *юл кисү* (Т.м.), *колак салу* (Т.м.), *койрык кысу* (Т.м.), *тел озайту* (Т.м.), *күз салу* (Т.м.), *җанны кыйнау* (Т.м.), *баштан чыгару* (Н.с.), *дөньяны тоту* (Н.с.), *зыян күрү* (Н.с.), *йөзе каралу* (Н.с.), *ләззәт алу* (Н.с.), *юл тоту* (Н.с.), *морадына йитү* (Н.с.), *хәйран калу* (Н.с.), *юлга төшү* Т.м.), *сүздән чыкмау* (Н.с.), *сүзен кисмәү* (Н.с.), *җан тыну* (Н.с.), *юл табу* (Н.с.), *телгә китерү* (Т.м.), к*үзне йомыб ачканчы* (Н.с.) һ.б.

Мәүлә Колый иҗатында да фразеологизмнар аз түгел. Аларның күпчелеге Мөхәммәдьяр поэмаларындагы мисаллар белән туры килә, әмма анда очрамаганнары да бар: *күңел бирү, кулдин китү, хәсрәт йоту, санга алмау, кулына алу, юлдин азу, күңел өзү, өмид өзү, күңел ору, ут йоту, күз тоту, кулдин килү, йөз чөерү, күз салу, гарешкә йитү, дөнья куу, күңел тулу* һ.б.

Бу әдипләр иҗатында очраган мисалларның күпчелеге XVIII йөз әдипләре әсәрләрендә дә, хәзерге татар әдәби телендә дә кулланыла. XVI – XVII гасыр поэзиясендә, хәзерге татар телендә кебек үк, кеше әгъзаларын белдерә торган кайбер атамалардан (авыз/агыз, баш, тел, кул, аяк, күз, колак, йөз) ясалган фразеологизмнар күп: *күзгә салу* ‘карау’, *күз салу* ‘карау’, *күз төшү* ‘карау, карап алу’, *күздин гаиб булу* ‘күздән югалу’( Мөхәммәдьяр), *күзгә алу* ‘карау’, *күз тоту* ‘исәп итү’, *күз салу*

‘карау’, *күзгә алу* ‘игътибар итү’. *Күңел, җан* компонентлы тотрыклы сүзтезмәләрне шагыйрьләр яратып куллана: *күңелен алу* ‘яхшы мөнәсәбәт уяту’, *күңел өзү* ‘тискәре караш барлыкка килү’, *күңел баглау* ‘кызыксыну уяну’, *күңелдән чыгу* ‘онытылу, хәтердән чыгу’, *күңелдин алу* ‘оныту, хәтердән чыгару’( Мөхәммәдьяр), *күңелдән китү* ‘онытылу’, *күңел бирү* ‘эшне тырышып башкару’, *күңел өзү* ‘бизү’, *күңел ору* ‘теләк бетү’, *күңелнең күзен ачу* ‘күңел бирү’, *күңел тулу* ‘хисләргә бирелү’, *күңелгә алмау* ‘теләмәү’ (М.Колый) һ.б. Фразеологизмнарның үзенчәлекле кулланылышка ия булганнары да бар. Мәсәлән,

Ил-улусны ус берлә тотты үзе,

Мәшрикъ вә мәгърибдә *йөрүр уш сүзе* .

Мөхәммәдьярның “Нуры содур” поэмасында кулланылган *сүзе йөрү* фразеологизмы хәзер *сүзе үтү* вариантында килә, ә йөр- фигыле белән *сүз йөртү* ‘гайбәт ташу, берәүнең сүзен икенче кешегә җиткерү’ (ТТАС, 2005:501) гыйбарәсе бар.

“Нуры содур” поэмасында Мөхәммәдьяр сигезенче бабны дөреслеккә багышлый һәм хикәятнең эчтәлеге “Һәр ки тотты телене котулды ул, Телене тотмаган уш тотулды ул” мәкале белән аваздаш. Тел сүзе белән ясалган фразеологизмнар урта гасыр әдәбиятында үк актив (Будагов,1869:371; Фазылов, 1971: 387). *Тел тоту* фразеологик әйтелмәсенең эчтәлегенә килсәк, борынгы төрки сүзлектә үк *тел* сүзенең ‘әсир’мәгънәсе бирелә (ДТС:559), М.Кашгарый сүзлегендә *jagyndan til tutty* ‘дошман телен тотты’ мисалы китерелә. Л.З.Будагов “Бабур-намә” әсәреннән китерелгән мисалга таянып, *тел тоту* ‘кирәк мәгълүматны алу максаты белән әсир алу’ фразеологизмын чагатай теленнән дип билгели (Будагов, 1868: 371). Бу истәлектә *тел тоту* һәм *тел алу* тотрыклы сүзтезмәләре синоним буларак кулланылалар (Благова, 1994: 143). Мөхәммәдьярның “Нуры содур” поэмасында *телене тоту* ‘эндәшмәү’ мәгънәсендә килә: Тотса ирде телене сахрада каз, Тотмаз ирде ул дәм ечрә аны баз (Мөхәммәдьяр).

XVI – XVIII гасыр поэзиясендә *баш* компоненты белән фразеологизмнар күп: Наданлыкдин үз *башына йиткәнләр* (Мөхәммәдьяр); *Гаклы китеб башындин*, йәшәрде күзе (Мөхәммәдьяр); *Чыкар башыңдин* тәкәббер, кылма иһмал (Мөхәммәдьяр); Йар ни дисә эймеш кабул әйләб, Нә бойура, тыңлар ирдем *башым салыб*(М.Колый); Мәүла Колый Хак эшендә *башың салгыл* (М.Колый); Төзәт имди үзеңи адәмгә охшаш, Яраткан хуҗадин *тартмагыл баш* (Г.Утыз Имәни); Әгәр гомрең улырса йилгә охшаш, Нәчек бөйлә йөрерсән *күтәреб баш* (Г.Утыз Имәни); Сәwәмен диб бөтенләй *сонмагыл ба*ш (Г.Утыз Имәни).

Истәлекләрдә *баш ору* гыйбарәсенең кулланылышы кызыклы. Хәзерге татар телендә аның мәгънәләре берничә: 1) башны бәрү, баш белән бәрелү; 2) түбәнчелек белән бөгелеп, баш ию хәрәкәте ясау; 3) үтенеп, ялварып сорау; 4) башны орындыру, терәү (ТТАС, 2005:76). Мөхәммәдьяр поэмаларында *баш ору* фразеологизмы түбәндәге мисалда килә: *Баш оруб кылды уш барча тапуг* (Н.с.). “Могҗизнамә” әсәрендә *баш ору* фразеологизмына *йөз ору* синонимы кулланыла: Хезмәтенә варыб, орыб йөзләрен, Сөйләделәр ул Рәсүлә сүзләрен (170). Л.Будагов та төрле төрки телләрдә һәм истәлекләрдә *баш ору*ның мәгънәдәш сүзтезмәләре күп булуын күрсәтә. Мәсәлән, *баш кую* мисалын янәшә куя (Будагов,1869:227). М.Колый хикмәтләрендә *баш кую* варианты кулланыла, әмма башка мәгънәдә бирелә: Биргел безгә тән төзеб, гакыл йулдаш, ихлас илә коллыгыңа *куймадык баш* (28б) (баш бирмәү, баш имәү). М.Колыйда “Башың йиргә оргыл Хакың коллыгына” (16 б) һәм ”Сәждәгә оргыл башың, аһ тию түккел яшең” мисалларында намаз укыганда башны җиргә ору хәрәкәте турында сүз бара. Рус язма истәлекләрендә *бить челом* беренче тапкыр XIVгасырда очрый һәм ‘приносить дар’, ‘сообщать’, ‘жаловаться’, ‘приветствовать при прощании’ мәгънәләрендә XV – XVII гасырда актив кулланыла. Галимнәр бу гыйбарәнең төрки

телләрдән кергәнлеген күрсәтәләр (Кулмаматов, 1994:109). XVI – XVIII гасыр татар поэзиясендә *йөз ору* сүзтезмәсенең семантикасы төрле: Торды заһид китмәгә *йөзүн оруб,* Калды бичин заһидка гозрен кулуб (Мөхәммәдьяр); Ул егетләр чөн бу хале күрделәр, Аягына төшүбән *йөз ордылар* (Могҗизнамә); *Йөзне йиргә ормадык*, Ни йөз берлә баргаймыз (М.Колый); Тәззариг кылыб, *йөзүм йиргә ордым* (М.Колый); Җөмлә мөрид хезмәтенә *йөз ормыш* ирде (М.Колый); Тәүбә берлә зар кылубән *Ора күргел йиргә йөз* (Габди); Аһ идүбән *йиргә орар йөзени* (Г.Утыз Имәни); Шаһ Морадның ишегигә *йөз орып* (Г.Утыз Имәни).

"Могҗизнамә" әсәрендә *баш ору, йөз ору* фразеологизмнарының саналган мәгънәләренең берничәсен *йөз тоту* тотрыклы сүзтезмәсе бирә: Налә әйләр *йөзене тотмыш* еwә 'юнәлү'; Бер кадәм ки *йөз тотыб* барса Аңа 'йөзен юнәлтү'; Кем аңа *йөз тотса*, мәхрүм улмас ул 'кемнеңдер ярдәмен өмет итү'. Бу әсәрдә 'карау ' мәгънәсен *йөз сөрү* сүзтезмәсе дә аңлата: Ошбу хаты анда чөнки күрделәр, Һәр бере ул сандыкка *йөз сөрделәр*. *Йөз сөрү* мисалы да бар: Бәс, Рәсүлнең күрекле йөзен күрделәр, Һәрбере аягына *йөз сөрделәр*. Өмми Камал иҗатында да *йөз тоту* 'юнәлтү' мәгънәсендә килә: Кем бу йула тәркилә *дотарса йөз* (1886, ).

Бу чорда *йөз* сүзе белән ясалган күп кенә башка фразеологизмнар да очрый. Хәзерге татар әдәби телендә урын алган *йөз чыту* варианты Мөхәммәдьярның "Нуры содур" поэмасында бар: Самит итеб өнәмәде һич сүзе, Күңлүнә агыр алыб, *чытмады йөзе* (не стеснятся) (Н.с.). Чат-фигыле Алтын Урда чоры язма истәлекләрендә дә очрый һәм 'сылтау, ялганлау, җыеру' мәгънәләрен бирә, шулай ук *каш чату* (каш җыеру) фразеологик берәмлеге составында "Хөсрәү вә Ширин" поэмасында кулланыла (Фазылов, 1971:510).

Мөхәммәдьяр иҗатында *йөз* компоненты белән ясалган башка фразеологизмнар актив кулланылышта: Сүзләмәкдә сән *йөземни ак кыл,*

Сүзләремни ил күңлигә йомшак кыл; Бисатин корсалар *дөнья йөзенә*; Рәуан шаһ төбгыда төште йөзин; *Иксүк улмагай йөзүңдин һич кара;* Сөфрасе кайнаб, *йөзидин рәнге китте*; *Йөзүндә калмады бер катрә каны*.

Шагыйрь иҗатында *йөзендә бер катрә каны калмады* гыйбарәсе очрый, аның мәгънәсен хәзерге татар телендә *йөзендә кан әсәре калмаган* фразеологизмы бирә. Мөхәммәдьярда шулай ук *йөзидин рәнге китү* (йөзенең төсе китү), *иңләре саргайу* (йөзе саргаю) фразеологик әйтелмәләрен дә очратабыз. *Йөз ак булу, йөз аклыгы, йөз аклау* фразеологизмнары кешене уңай яктан күрсәтә торган әйтелмәләр. Бу автор иҗатында урын алган мисаллар арасында *йөз карасы, йөз каралу* кебек аларга капма-каршы мәгънәлеләре дә бар: Иксемәсүн *йөз караси* ( йөз карасы кимемәсен, китмәсен); Бу балык берлә *карарды бу йөзүм*; *Йөзүң кара*, җәһәннәмнең эти сән. XVII-XVIII йөз әдипләре иҗатында да мондый мисаллар еш очрый: Гыйлем йук, *йөзүм кара* (М.Колый); *Йөзе кара* Түкәл өчен Изге дога кылыңыз (Габдессәлам). Әсәрләрдә бу гыйбарәнең фарсы варианты да урын ала: Бар ирде бер гасыйм *руйе сийаһ* (Мөхәммәдьяр). XVIII гасыр шагыйре Г.Тайсугани касыйдәсендә дә бар (XVIII гасыр татар ..., 2006:33)

Гадәттә, ачык йөзле дип мөлаем, сөйкемле, көләч кешегә әйтәләр һәм аны уңай яктан сыйфатлыйлар, ә Мөхәммәдьярда ул нәкъ шул мәгънәдә килсә дә, кешене тискәре яктан характерлый:

Ачук йөзүң берлә безне алдайурсән,
Мәне сәүгән баки калу тиб әйүрсән.

Җыеп әйткәндә, XVI – XVIII йөзләр поэзиясендә фразеологик әйтелмәләр куллануга зур игътибар бирелә. Аларны ныклап өйрәнү төрки халыкларның, аерым алганда, татарларның милли-мәдәни

ӘДӘБИЯТ

1. Благова Г.Ф. “Бабур-наме”: Язык, прагматика текста, стиль. К истории чагатайского литературного языка. – М.: «Восточная литература» РАН, 1994. – 404 с.
2. Будагов Л.З. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий. - Т. I - Спб., 1869. – 810с.
3. Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари. Шигырьләр, поэмалар / Төзүчесе Ә.Шәрипов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1985. –397 б.
4. XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. – Казан: “Дом печати” нәшр., 2006. – 363 б.
5. Кулмаматов Д.С. Бить челом // Русская речь. – №1. – 1994. –С. 109-113
6. Мөхәммәдьяр. Нуры содур. Поэмалар, шигырь. – Казан: Татар. Кит.нәшр., 1997. – 336 б.
7. Мәүла Колый. Хикмәтләр. – Казан: “Иман” нәшр., 19
8. Татар теленең анлатмалы сүзлеге. – Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2005. – 848 б.
9. كتاب ام كمال. – Казан, 1898.